
Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

Чаян



9

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ СЕНТЯБРЬ * 2022 * КАЗАН

Александр ШУЛЬПИНОВ



Алмаз **ХӘМЗИН**

АПТЫРАГАЧ, ШУЛАЙ, ДИМ...

Хәтер кала күп нәрсәгә:
Ник юньле тормыш килми?
Сүгеп атар идем барсын...
Ярый ла ачу кими.

Үпкәлимен җәмгыятькә,
Картлыкны беркем сөйми.
Аяк сузганчы эшлибез –
Ярый ла ачу кими.

Үч аласым бар байлардан,
Ходай да берни күрми.
Күзләрен йоммый талыйлар...
Ярый ла ачу кими.

Өзәр идем чылбырларны,
Мин бәйдәге этмени?
Ул, ичмаса, өрә ала...
Ярый ла ачу кими.

Сәдакага эшлибез бит –
Хөкүмәт күп түләми.
Теш кайрап йөрим шуңа,
Ярый ла ачу кими.

Телен өзеп атар идем,
Депутатлар күп сөйли.
Бер юньле эш кыралмыйлар,
Ярый ла ачу кими.

Йодрык төйнәп йөрим әле,
Олигархка кул тими.
Күренгәннәре юк илдә,
Ярый ла ачу кими.

Пыр туздырырга әзермен –
Министрга тел үтми:
Эшен юньләп эшли белми –
Ярый ла ачу кими.

Үземне дә сүгеп атам –
Ни әйткәнне тел белми.
Аңа да чара күрерләр –
Ярый ла ачу кими.

Әйткәнемне яратмыйлар,
Язганым – дөрес килми.
Гел ялган белән яшибез,
Ярый ла ачу кими.

Юкка чыгар идек күптән
Дөреслеккә тиенми.
Хәвефләрдән арынмас баш –
Ярый ла ачу кими.

Юрий **КУХАРЕНКО**





ШОМБАЙ *болай диде...*

Хөрмәтле Чаян! Хәзер подъезд ишекләре һәм иҗтимагый челтәрләр "теләсә нинди бурычларны юкка чыгарабыз" дигән белдерүләр белән тулы. Миңа калса, монда ниндидер хәйлә һәм ялган яшеренгән. Ничек инде банк йә ЖКХ бурычын "юкка чыгарырга була"? Бу күбрәк фантастикага охшаган. Әйе, бүгенге байлар акча ясар өчен ниләр генә уйлап чыгармыйлар...

Л. ТАҺИЕВ

БӨГЕЛМӘ

– "Теләсә нинди бурычлар" – бу чынлап та фантастика өлкәсеннән, мин моның белән риза, – диде Шомбай ага, укучыбызның хатын укып чыккач. **– Башта ирлек бурычын юкка чыгарырга тырышып карасыннар иде...**


Ринат АБЗАЛОВ

КАРА ҖИР


Үҗәтләнеп, кара җир өстенә
Бәреп чыга яшел үсенте,
Сабакларда гөлләр чәчәк ата,
Шулай була җәен җир өсте;
Тау үрләрен баса җир җиләге,
Кызыл төскә манып дөньяны,
Җир тукыган келәм-болыннарның
Зәңгәр, сары чәчәктер җаны.
Кара җирдән туа барча төсләр,
Әйтерсең лә гүя бер кыйсса.
Бу бит җыр йә шигырь генә түгел,
Бу – үзе бер сихри могҗиза.

Кем ул әйтә, җирне "кара" диеп,
Кара җир ул – безнең бәрәкәт.
Җирнең кара булганына күрә
Яши кеше җиңел һәм рәхәт!

Ринат АБЗАЛОВ



Игорь КИЙКО



Хәвефле ләззәт

"Идел бит ул, тирән бит ул, тирән бит ул, киң бит ул", – дип сокланып җырлаган халык элек-электән. Чынлап та, судан башка тормышны күз алдына китерү мөмкин түгел. Бигрәк тә җәй көне. Эссе көндә шул ук Иделнең, һичьюгында Казансуның салкынча суына чумып чыкмыйча ничек түзәсең ди. Ходайның рәхмәте белән башкалабыз шул елгаларның ярларында урнашкан бит. Өстәвенә, тирә-юньдә күпме күлләр. Суда йөзеп, алтынсу комда аунарга яратучылар өчен чын оҗмах бит! Ләкин, кызганыч, шундый елгалы шәһәрдә коенырга урын юк. Үзенең елга-сулары белән горурланучы республикада да пляжлар белән бәла!


Ел саен, коену сезоны башлану белән, суны сагынган халык абына-сөртенә елга ярларына омтыла. Тик аларның юлына сандыктан чыккан әкияти баһадирлардай, Роспотребнадзор һәм МЧС чыгып баса. Һәм һәрвакыт, кояш суккан кебек, бер үк нәрсә – коену тыела! Сәбәпләре төрле – суның сыйфаты начар, елга-күлнең төбе тиешенчә өйрәнелмәгән, кием алыштыру кабинкалары, чүп контейнерлары һәм бәдрәфләр юк, коткару чаралары һәм коткаручылар үзләре җитми...

Теләкләрен тыя алмаучылар, башкаладан чыгып, рөхсәт ителгән сусаклагычларга сузыла – мәсәлән, Аккош күленә йә Лаешка – халык телендә Кама диңгезе дип аталган урынга. Ләкин монда да шул ук уяу "баһадирлар" калкып чыга! Коенучыларның саны күп булу сәбәпле, суның сыйфаты нормаларга туры килми. Һәм җәй буе шулай – пляжларны бер ачалар, бер ябалар. Әмма күп кенә сабырсыз шәһәр халкы, тыюлар һәм катгый киңәшләргә төкереп, башлары белән беренче туры килгән суга ташланалар. Моның нәрсә белән тәмамлануы һәркемгә билгеледер дип уйлыйбыз. Быел гына да ярты ел дәверендә генә Татарстанда 69 кеше батып үлде, аларның 8-е – балалар.

Бу очракларда гадәттә тыңлаусыз коенучыларның үзләрен гаеплиләр: имеш, җиһазландырылмаган урыннарда коенмаска иде. Ә елга-күлләргә бай республикада җиһазландырылган урыннар юк шул. Бүген ватаныбыз диңгезләренә бару бәяләре дә якын килә торган түгел. Төркия белән Мисырдан да уздырып җибәрделәр! Бөтен тиешле әйберләр белән тәэмин ителгән берничә пляж ясарга нәкъ вакыты бит югыйсә. Гомумән, мөмкинлегем булса, "Халык пляжы" дигән программа игълан итәр идем. Казан янындагы Идел ярына, законсыз үзләштерелгән ярларны каплап торган коймаларны алып атып, ком ташытыр идем. Һәм берниндиСочи да кирәкми! Халык миңа рәхмәт укыр иде...


Ә эсседән җебегән баш миләрен еллар буе борчыган – нигә соң бер пляжны да тәртипкә китерә алмадылар дигән сорауга җавап үтә гади. Казан туристларны беренче чиратта тарихы, мәдәнияте һәм матур кыяфәте белән кызыксындыра. Пляжда ял итү бу исемлеккә керми, шуңа күрә җирле елга-күлләргә зур суммалар түгүнең әллә ни мәгънәсе юк, чөнки бу сезонлы бизнес, аннан ел әйләнәсендә акча каеру мөмкин түгел. Һәм коену сезоны казанлылар өчен хәвефле ләззәт булып кала бирә. Суга чумып чыгуның бәясе – йә штраф, йә берәр нинди кизү эләктерү. Бу әле иң кулай очракта...

Людмила САФИУЛЛИНА




Александр АЛЁШИН

Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Вячеслав ШИЛОВ





• • •

Безнең илдәге түрәләр ике категориягә бүленә – намуслылар һәм инде эләккәннәре.

• • •

Әбисе оныкчыгына Пушкин әкияте сөйли:

– Яшәгән ди зәңгәр диңгез буенда карт белән карчык...

– Әбием! Галкин – бабаймыни?

• • •

Контактта – 300 дустың. Туйда – 80. Туган көнеңдә – 10... Ә инде бәла килсә – барлыгы 2 әү... Алары да әле аның әти-әниең булыр.

• • •

Тормышның ачы хакыйкате: пирожки сатып, әби кеше үзенә ипилек эшләде.

• • •

Кызы әнисенә шалтыратып зарлана:

– Әни, минем кадеремне белмәгән ирем карабодай боткасын ашамаска тели!

– Кызым, син аның өчен пешергәндә бик тырышканыңны сөйлә!

– Аны пешерергә кирәкмени?!.

• • •

Барысы да халык өчен. Начар күрүчеләр өчен – күзлек. Саңгырауларга – колак аппараты. Акылсызларга – акыл өйрәтә торган интернет...

• • •

– Сәләт үстерә торган уенчыклар бармы?

– IPhone 13.

– Нәрсәне үстерә ул?

– Көнчелекне!

• • •

Куллары бөтен нәрсәне булдыра торган берәү башы авыртучыга өйләнгән. Хәзер авыру баш кулларга тынгы бирми.

Абау!

ЯҢА РЕКОРД

Татарстанда алкоголь сату буенча соңгы тугыз ел эчендә рекорд куйган. Республикада эчелгән хәмер күләме 6 процентка, ягъни 2,61 дән 2,75 миллион декалитрга кадәр арткан. Тамак чылатырга яратучыларның күбесе Питрәч һәм Югары Ослан районнарында, ә андыйларның иң аз саны Мамадыш һәм Теләче районнарында яши икән.

ХОКУКСЫЗ ТАНЫКЛЫК

Россиянең Татарстан буенча Тикшерү комитеты элекке ЮХИДИ инспекторына карата җинаять эше кузгаткан. "Эш" өчен 10 нан 100 мең сумга кадәр алып, ул системага праваларның югалтылган булуы һәм алыштырылырга тиешлеге турында мәгълүмат кертеп барган. Ә аннан соң укымаган һәм имтихан тотмаган килеш клиентларга правалар өләшкән. Шулай итеп, 81 кеше, интекмичә генә, автомобиль йөртү таныклыкларына ия булган. Алар арасында наркологта теркәлгән һәм праваларыннан мәхрүм ителгәннәр дә булып чыккан. Ә инспектор исә 1,5 миллион сум өстенә берничә җинаять статьясы да алган.

ЯЛГАН ПЕНСИЯ АГЕНТЛАРЫ


Чаллыда биш үткен бәндә кешенең пенсияләрендә акча ясарга маташып караганнар. Үзләрен дәүләтнеке булмаган пенсия фонды агентлары дип белдереп, алар гражданнар белән 23 мең чамасы мәҗбүри пенсия страхованиесе турында ялган килешенүләр төзегәннәр. Алар белән эш иткән клиентлар барлыгы 42 миллион сум югалткан.

ТОРАК БЕЛӘН ХУШЛАШУ

Казандагы Салмачы бистәсендә яшәүче ике йөз гаиләнең бердәнбер торакларыннан колак кагуы мөмкин. Аларның йортлары газүткәргеч урнашкан зонада булып чыккан, һәм хәзер газ хезмәте аларның сүтелүен таләп итә. "Элек кая караганнар соң алар? Төзергә нигә рөхсәт биргәннәр? Нигә хакимият тыюлы зонада җир өләшкән һәм төзелгән йортларны теркәгән?" – дигән гадел сораулар бирә кешеләр. Ә судта аларның торакларын юкка чыгару турында карар кабул ителгән инде.

ТУГАН КИҢЛЕКЛӘРЕН ТАШЛАП КИТӘ

Җырчы Элвин Грей, чынлыкта Радик Юльякшин, Татарстан һәм Башкортстанда эшчәнлеген тәмамлавы турында белдерде. Ул, Мәскәүгә күчеп китеп, бары тик русча җырлар гына башкарачагы турында хәбәр итте. Ике республиканың атказанган артисты шулай ук аның тамашачыларын татар һәм башкорт телендә башкарылачак соңгы җырлары көтүе турында да белдерү ясады. Бу аның "милли эстрада киңлекләрендә үткән 16 еллык иҗади юлының нәтиҗәсе" булачак.



Валерий ТАРАСЕНКО



Александр АЛЁШИН

Вячеслав ШИЛОВ



ЮБИЛЕЙ УҢАЕННАН

Ринат МӘННАН –
Алмаз Хәмзинга

Сатира-юмор остасы,
Көләч йөзле Х. Алмаз.
Җир шарында җитешсезлек
Тәмам бетте дисәләр дә,
Үткен темасыз калмас!



Александр БРЮХАНОВ

АВЫР МӘСЬӘЛӘ

Әйбәт кыз белән ничек танышырга?

Аннан соң, аның әйбәт икәнен каян белергә? Бәлки ул әйбәттер дә, тик үзе кебек фабрикада балык чистартучылар, йә метрода эшләүче контролёр кызлар арасында гына...

Ә танышуны нәрсәдән башларга?..

Бәлки турыдан-туры: "Әйдәгез танышыйк" дип әйтергәдер? Алай итсәң, "вәт нахал!" дип уйлавы мөмкин... Йә шунда ук муенга ташланып, аны сындырып ташлавы бар...

Сез бүген искиткеч гүзәл дисәң, нинди тәрбиясез дип уйлавы мөмкин...

Ярый, таныштың ди, ә аннан соң нишләргә? Кая алып барырга? Әгәр филармониягә чакырсаң, "анда бит инде күптән беркем дә йөрми", дип көлүе мөмкин, ә кулга-кул тотынышып болай гына йөрсәң, акчасы юк дип уйлавы бар.

Ә төнге клубка барырга тәкъдим итсәң, "мондый оятсызлыкны синнән көтмәгән идем", дияр...

Ә шулай да, барса, нигә шулай җиңел ризалашты, дигән сорау туа. Һәм ул ризалашкан нәрсәгә акча җитәрме? Ә җитмәсә, һәркем үзе өчен түли, дияргә була анысы.

Ә җитсә, соңыннан нишләргә?


Өеңә алып кайтсаң, аның анда бөтенләйгә калуы да бар шул...

Аңа ияреп кайтсаң, ә ул шуны гына көткән булса?..

Йә берни булмагандай аерылырга...

Их, авыр да инде әйбәт кыз белән танышу...

Егетнең куркуына кызның шикләнүе генә каршы чыга ала: «Минем белән тагын нишләргә дә белми торган аннан моның нәрсә белән тәмамлануын күз алдына китерә алмаучы мокыт танышырга тели».



Василий АЛЕКСАНДРОВ

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

- Өйләнгән ир һәрчак салкын акыллы була, чөнки аның өйләнү турында уйлап баш катырасы юк.
- Яшьлек – олыгаеп килүчеләр өчен зур җитешсезлек.
- Әгәр ирләр хатыннардан җитдирәк күренсәләр дә, бу – киемнәре караңгырак төстә булу аркасында гына.
- Юләрлекләр ясарга курыкмаган кеше үзен яшь дип саный ала.
- Хатын белән бәхәстә җиңүнең бердәнбер ысулы – аны башламау.
- Хатын-кызның шиге шиксез фактлардан төгәлрәк.
- Өметкә өйләнәләр, вәгъдәгә кияүгә чыгалар.

(Хатын-кыз белгечләре мәҗлесендә язып алынды.)

Алмаз ХӘМЗИН

Дөнья кая тәгәри?..

Август ае – бирә Ходай җәйнең ямьле көннәрен. Бер ай чираттагы ялым булса да, көн дә эшкә киләм. Кемнәр Төркиягә барган, кайсылары – Абхазиягә. Һәммәсеннән сорыйм:

– Кайда ял иттең?

– Каян беләсең? – диләр.

– Төсеңә карап. Йөзең – кояш, тәнең – кучкыл, борының көйгән...

Берсенә карап-карап тордым да болай дидем:

– Абхазиядә булдыңмы әллә?

– Сизеләмени?

– Әйе.

– Ничек?

– Абхаз шәрабләрендә коенгансың... Әле дә аңкып тора...

– Димәк, үзең дә кайчандыр авыз иткән булгансың...

– Бочкасына төшмәсәк тә, беләм, шул якларда хезмәт иттем – армиядә.

Бер чибәркәйнең эштә күптән күренмәвенә шигем төшеп йөри иде. Әнә үзе килә. Һай, атлаулары – ашый җанны!..

– Сеңлем, Камбоджада ял иткәнсең, ахрысы, загар особый!..

– Бери дальше! – ди бу миңа, үтеп барышлый, аякларын килешле-килбәтсез атлап. Янәмәсе – модель!

– Багам утрауларындамы?

– Әйтмим. Шефтан сора! – ди бу. Дәрәҗәсен күтәрергә маташуымы соң?

– Нужәли лилипутыгыз белән?..

– Ибраһимны әйтәсеңме?

– Соң... Әйбәт егет бит! Ике генә хатыны, ике генә баласы бар.

– Бери выше! – ди бу миңа, бармагы белән күккә төртеп. Шулай ук микәнни, дип, Сөембикә манарасы торган якка карап куйдым. Әйе-е-е! Кешеләр ял итә. Кем ничек, кайда? Кем белән?.. Ни төсле?.. Ә мин – аптырашка калган журналист, уйга баткан... Каян акча табалар?

Бер хезмәткәр кызыбыз:

– Ел буе җыеп бардым, – ди. – Мин бит ялгыз – кияүгә чыкмаган, – дип өстәп тә куйды. Балалар үстерергә түгел, шул – елга берәрсе белән диңгездә коеныр өчен генә яши микәнни? Егетләр дә җәй көннәрендә бик күренмиләр... Шулар янында йөриләрдер инде.

Ә мин монда: "Дөнья кая таба тәгәри?" дигән уйга чумып, "Чаян"га мәкалә язып утырам – сәдака акчасына...

Валентин ДРУЖИНИН



Николай ВОРОНЦОВ





Мари ядкаре



Мари Илен һич шикләнмичә юмор республикасы дип атарга була торгандыр. Беренчедән, монда – Козьмодемьянск шәһәрендә ел саен “Бендериада” дип аталган юмор һәм сатира фестивале уздырыла. Икенчедән, республика үзенең “Пачемыш” юмористик журналы белән бөтен илдә билгеле. Өченчедән, озак еллар дәвамында журналны һәм фестивальне безнең дустыбыз һәм каләмдәшебез, халык юморы традицияләрен саклаучы Виталий Шкалин җитәкләп килә.

Иҗат юлын “Чаян”да башлаган мари халкының баш юмор остасы – күпсанлы китаплар, шулай ук фельетоннар, хикәяләр авторы. Аларның берничәсен укучыларыбызга тәкъдим итәбез.

Виталий ШКАЛИН

СТРАУСЛЫ КОНВЕРТ

Хәл катлауланганнан-катлаулана барганга күрә гадәттән тыш чаралар күрү кирәк иде. Һәм Вадим Витальевич ришвәт бирергә булды. “Ә нәрсә? – дип уйлады ул. – Каты бәгырьле Кусин янына керергә дә өстәленә конверт куярга. Семёновтан алган, диләр. Кошкиннан алган. Миннән дә алыр”.

Вадим Витальевич страус сурәтләнгән конверт сатып алды һәм анда гаилә бюджетыннан калган акчаларны салып куйды. Фатир өчен түләмәгәнен исенә төшереп, берсен кире тартып чыгарды.

Бинага кереп, Вадим Витальевич тиешле ишекне тапты, шакыды һәм ачып җибәрде. Кусин нигәдер кәнәфидә түгел, ә өстәл янында урындыкта утыра иде.

– Иртәгә минем мәсьәлә каралачак, – диде дулкынланып Вадим Витальевич.

Кусин аңа кызыксыну белән карап алды.

– Мин аның уңай хәл ителәчәгенә гарантия бирә алмаганыгызны аңлыйм, әлбәттә, тик шулай да...

Вадим Витальевич кесәсеннән страуслы конвертны чыгарды һәм аны Кусин алдына – журнал өстәлчегенә куйды.

Кусин берсүзсез конвертны пиджагының сул кесәсенә салып куйды.

“Менә! – дип җиңел сулап куйды Вадим Витальевич. – Ә мин, җүләр, борчылган идем”.

Кусин ул арада торды һәм кабул итү бүлмәсенә чыгып китте.

“Кара син аны! – дип уйлап куйды Вадим Витальевич. – Саклана үзе тагын. Акчаны эш урынында тотмый. Әлбәттә, нинди тиле акчаны эш бүлмәсендә тотсын ди?”

Кинәт ишек ачылды, һәм таныш булмаган ир килеп керде. Вадима Витальевичны күреп, ул гаҗәпләнде:

– Сез минем янгамы?

– Юк. Мин Кусинга.

– Соң Кусин мин булам бит инде.

– Сез?!

– Әйе! Сезнең алдан минем янга берәү кереп чыкты инде. Сез аны күргәнсездер бит?

...Вадим Витальевич инде берни дә ишетми иде. “Ярый әле, фатирга дигән акчаны калдырганмын!” – дип тынычландырды үзен Вадим Витальевич һәм коридор буйлап чыгу ягына атлады.

ӘҢГӘМӘ ҮТКӘРДЕ

Хуҗалык җитәкчесе Шалупаев фермага керде, анда Зинаны күреп, янына килде.

– Исәнме, Зина! Тагын санэпидстанциядән шалтыраттылар. Әгәр фермада елгага пычрак ташлауны туктату турында әңгәмә үткәрмәсәгез – штраф салам. Шуңа күрә, Зина бәгырькәем, тыңла һәм мыегыңа чорнап бар. Әлбәттә, безнең көмештәй саф елгабызны пычратырга ярамый. Аңлыйсыңмы?.. Кыскасы, иртәгәдән ферманың бер бөртек пычрагы да елгага эләгергә тиеш түгел. Килештекме? Килештекме, мин сиңа әйтәм?!.. Әйтер сүзең юктыр шул. Ләкин исеңдә тот: тагын бер кат мин килгәндә шундый хәлне күрсәм – җәза каты булачак! Бик каты – аңладыңмы?!. Ярый, бар инде урыныңа...

Шалупаев аны, назлап, сыртыннан сыйпап куйды, җылы күкрәгенә кулын куеп алды, һәм, мөгезләреннән тотып, аранга таба этәрде.

КИРӘГЕН БИРДЕ

Һәр кешенең дә гомерендә “Булды, җитте!” дигән карар кабул итә торган мизгел җитәдер.

Щавелкин үзенең тыгыз җилкәләрен капшап алды, учына төкерде дә... турыдан-туры нәчәлнигенә таба юнәлде.

– Хөрмәтле Леонид Петрович, мөмкинме, мин сезгә бераз... сугып алам?

Һәм җавап көтмичә, чәпеп җибәрде! Аннан соң тагын, тагын... Башта шөлләбрәк торса да, тик соңрак Щавелкин гамәлнең тәмена керде. Корсагына да ялтыратты, җилкәсенә дә, ә Леонид Петрович йөзен куллары белән каплап, арты белән борылгач, сыртын дөмбәсли башлады. Бөеренә дә, умырткасына да...

“Бу сиңа түләнмәгән өстәмә эш өчен!”

“Монысы декабрьдәге отпуск өчен!”

“Ә бу узган елгы шелтә өчен!”

“Ә монысы...”

– Булды, булды, мәрхәмәтсез! – диде хәлдән тайган Леонид Петрович. – Җитте! Җәллә мине, Щавелкин!

“Кара син аны, җәллә дигән була”, – дип уйлады Щавелкин, авыр сулап һәм тирләгән маңгаен сөртте.

– Утыр! – диде Леонид Петрович, янәшәсенә күрсәтеп. – Ә ятсаң тагын да шәбрәк булыр, уңайлырак. Хәзер мин синең кирәгеңне бирәчәкмен. Ул себеркене кайнар суга тыгып алды, бераз тын алды һәм Щавелкинның сыртын чаба башлады. Тегесе ләззәтеннән ыңгырашып кына куйгалады.



Вячеслав ШИЛОВ



Илья КРИШТУЛ

ШКАФТАГЫ РӘСЕМ

Лепёшкинның тормышы балалар бакчасындагы шкафка ябыштырылган рәсем белән билгеләнгән иде.

Ул нәрсә эшләсә дә, кая омтылса да – барыбер шул ачык төсләр белән ясалган сурәткә барып төртелде. Дәресләрдә балалар пластилиннан шкафларындагы рәсемне ясыйлар, Лепёшкин да, нәфрәтләнеп, шул күңел кайтаргыч яшелчәне әвәли иде, ә тәрбияче аны күзләре горурлык белән балкыган әти-әнисенә тапшыра иде. Бөтен маскарадларда һәм Яңа ел бәйрәмнәрендә Лепёшкин бары тик шул шкафтагы сурәт костюмына киенде. Лепёшкин каршы килергә дә тырышып карады – ләкин бакча баласы язмыштан узмыш булмаганын әле белми иде. Берзаман ул прогулкага чыгар алдыннан Лена Кругловaның әйберләре яткан шкафны ачып, өстенә аның кызлар күлмәген, оекларын һәм туфлиләрен киде. Җәнҗал купты, почмакта басып торырга туры килде, һәм шуннан соң, аның җенси юнәлешендә шикләнеп, Лепёшкинны бик озак балалар психологы янына йөрттеләр. Психолог нормадан тайпылышлар тапмады, бала яшелчәләр һәм җиләк-җимешләрне бутамасын өчен, бакчадагы кебек, өйдә рәсемнәр элеп куярга кушты. Һәм Лепёшкин тынычланды…

Мәктәптә укыганда ул ун ел буе иң арткы партада утырды, дәреслекләр укып башын катырмады, ә бертуктаусыз уйчан карашы белән тәрәзә аркылы мәктәп янындагы "Гастроном"ны күзәтте. Укытучыларның "Кая карап утырасың, Лепёшкин?" дигән соравына ул: "Әнә, "Гастроном"га яшелчә кайтартканнар, бушаталар…" – дип җавап бирә иде. "Берәр китап укыр идең, ичмасам, алайса үзең дә яшелчә булып үсәсең бит…" – диләр иде укытучылар, һәм көрсенеп, аңа "өчле" куялар иде.

Мәктәпне тәмамлагач, Лепёшкин укырга керергә тырышып маташмады, ә шул мәктәп янындагы "Гастроном"га йөкче булып урнашты. Анда ул булачак хатыны – яшелчә бүлегендә сатучы булып эшләүче Наташа белән танышты. Кайнар хисләр аның да Лепёшкин йөргән бакчага йөргәнлеге ачыклангач кабынып китте. Наташаның да шкафы шундый ук – яшелчә сурәте белән булган икән. Алар өйләнеште, бу вакыйгадан соң Лепёшкин "яшелчә читлеге"ннән чыгып, машинистлыкка укырга керергә тырышып карады, әмма имтиханга соңга калып, курсларга элгә алмады. Аның моңа хәтта кәефе дә кырылмады – чөнки тормыш тәҗрибәсе язмышны алдап булмаганын аңа аңлаткан иде инде.

Кайчагында, смена беткәч, көнбагыш алып, алар хатыны белән бергәләшеп үзләренең бакчалары янындагы эскәмиягә барып утыралар иде. Һәм шкафтагы рәсемнәрнең башка булса ни булачагын күзаллап, хыяллана башлыйлар. "Әнә, Лена Кругловaның финик ясалган иле, һәм ул Израильгә яһүдләр һәм финиклар янына китте…" – ди Лепёшкин. "Ә Ольга Ивановaның ике кавын ясалган иде, һәм аның күкрәкләре бишенче размерга кадәр үсте. Аны депутат хатын итеп алды… Мин бит, сизенгәндәй, аның белән шкафларны алышырга теләгән идем бит!" – дип җавап бирә Наташа.


Соңыннан, "Гастроном" супермаркетка әверелгәч, анда чит илләрдән йөк ташучылар килде, ә Наташаны сәүдә залының менеджеры итеп күтәрделәр. Лепёшкинны да куып чыгармадылар. Аңа яшелчә костюмы бирделәр, һәм ул аны киеп бик озак ниндидер акцияләр турында кәгазьләр таратып торды…

Шулай да, нинди яшелчә иде соң ул?

"Җир астында алтын казык, нәрсә ул, балалар?" – дип сорый иде тәрбияче апа. "Кишер!" – дип кычкыралар иде балалар һәм сәхнәгә кишер костюмы кигән өч яшьлек Ванечка Лепёшкин килеп чыга иде. Шушы сәхнәдән ул, костюмын да салып тормыйча, турыдан-туры үзенең озын соры тормышына атлады…

Кызык, ә минем бакча шкафында нинди рәсем булган икән? Әни әйтә: шаян җил белән тулы ак җилкәнле диңгез корабы, ди, ә тёща — соры төрмә бинасы, ди.

Мин әнигә ныграк ышанам…



Игорь КИЙКО

Илдар НӘФИЕВ



Василий АЛЕКСАНДРОВ





РАСЛЫЙ АЛМАГАН

Мәскәү дәүләт инспекторларының матди хәленнән көнләшергә генә мөмкин! Менә шулай, гап-гади ЮХИДИ инспекторының 23 күчемсез милке булганы ачыкланган, аның 7 се Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә һәм Болгариядә урнашкан. Ә банклардагы счетларда ул 48 млн. сум, 60 мең доллар һәм 24 мең евро саклаган. Тик менә мондый байлыкның законлы булуын экс-инспектор раслый алмаган. Барлык аңлаешсыз юл белән эшләп алынган акчалар дәүләткә күчкән.

ЗАКОНСЫЗ ЗАКОНЛЫЛЫК

Федераль җәзаларны үтәү хезмәте системасында масштаблы тикшерү уздырылган һәм ул юкка гына түгел. 2022 елның алты аенда пенциар система эшендә 85 меңгә якын хокук бозу ачыкланган. 97 җинаять эше кузгатылган, ә 27 меңгә якын кеше дисциплинар җаваплылыкка тартылган. Урыннарда тәртип урнаштырганнан соң, югарыдагы закончыларга да алынганнар – җинаять-төзәтү системасында законны үтәргә тиешле прокурор хезмәткәрләренә чираттан тыш аттестация уздырылган. Зәңгәр мундирларның кайберләре үз кәнәфиләреннән колак каккан, күбесен үз вазыйфаларында түбәнәйткәннәр.

АШЫГЫЧ ЯРДӘМ

Үлгән кешеләр турында мәгълүматны ритуаль агентлыкларга җиткерүче ашыгыч ярдәмнең намуссыз хезмәткәрләре турында берничә тапкыр язылган иде. Чиксез бу картинага тагын бер штрихны Оренбургтан ашыгыч ярдәм хезмәткәре өстәгән. Ул компьютерга яңа мәрхүмнәр турында мәгълүматны автоматик режимда тапшырган программа урнаштырган. Язмыш ирониясе буенча, «уйлап табучы» мәгълүмати куркынычсызлык өчен җавап бирүче булган. Ритуалчылар, мондый ашыгыч ярдәмнән һәм мәрхүмнәрнең туганнарының шок хәленнән файдаланып, үз хезмәтләрен югары бәядән тәкъдим иткәннәр. Мондый санкцияләнмәгән апрейд өчен алдынгы белгеч сигез елга кадәр интернетсыз калырга мөмкин.

ЙОМШАК ХОКУК БОЗУЧЫ

Екатеринбургтан пассажиры каешын эләктермәгән өчен, машина йөртүчегә штраф килгән. Әмма пассажир булып тәрәзәгә ябыштырып куйган уенчык мәче Саймон булган. Ни өчен күзәтү системасының йомшак уенчыкны реаль пассажир дип кабул итүе табышмак булып калган. ЮХИДИ хезмәткәрләре үз хаталарын таныган, әмма штрафны гамәлдән чыгарырга җыенмаган. Штрафка тартылганның хөкем карарына карата шикаять бирү өчен законлы ун көн булуы белән аңлатканнар.





ЧАЯН ШИФАХАНӘСЕ


Виктор ФЁДОРОВ



Вячеслав ШИЛОВ



Юрий КУХАРЕНКО



• • •

Табиб берәүнең колагын дәвалый.

– Рәхмәт сезгә, доктор, мин күпме тиеш?

– Ике мең сум.

– Күпме, дидегез? Җиде мең дидегезме?

– Әйе, әйе, җиде мең!

• • •

– Доктор, мин әллә ничә табиб янында булдым. Аларның берсе дә сез куйган диагноз белән ризалашмый.

– Кемнең хаклы, кемнең хаксыз икәнен ярып карагач белербез алайса.

• • •

Әнисе кечкенә кызын табиб янына алып килә:

– Доктор, зинһар, ярдәм итегез, кызымның күзләре һәм авызы ябылмый!

Кызны карагач, табиб:

– Икенче юлы балагызның чәчен болай тарттырып үрмәгез!

Виктор ВЕСЕЛОВ

УҢАЙ ФИКЕР ЙӨРТҮ

Пациентның моң-зарларын тыңлаганнан соң психотерапевт ханым болай диде:

– Иван Иванович! Сез тирән депрессия кичерәсез. Аннан чыгар өчен, уңай фикер йөртергә өйрәнергә кирәк. Менә чит ил кешеләреннән үрнәк алыгыз. “Хәлләр ничек?” дигән сорауга алар, елмаеп, «О’Кей!» дип җавап бирәләр. Хәлләре бик шәптән булмаганда да.

– Әйе.

– Алайса тренинг башлыйбыз. Мин сорыйм, сез җавап бирәсез. Тормыш ничек?

– Әй, тормышмыни бу?!

– Мин аңлаттым ич... Сез болай итәргә тиеш...

– Әлбәттә, тиеш! Банкка – кредит өчен, тёщага – кызының харап ителгән тормышы өчен...

– Өр-яңадан башлыйбыз! Иван Петрович, тормыш ничек? Йә?!

– Ничек... О’Кей! Дүшәмбе көн эштән кудылар, сишәмбе көн хатын ташлап китте. Төннәр буе йоклый алмыйм. Уйланып ятам...

–Иван Петрович! Һәр хәлнең уңай ягын таба белергә кирәк. Аңладыгызмы?

– Аңладым шикелле.

– Хәзер тикшереп карыйбыз. Тормыш ничек?

– Хет әйләнеп кит! Сезгә барганда абынып егылдым, теземне имгәттем.

– Менә бу шәп! Уңай нәрсә таптыгыз бит!

– Кайда?!

–Аңлашылмыймыни? Тезегезне имгәткәнсез, ә аягыгызны сындыруыгыз мөмкин иде.

– Мин аны инде биш тапкыр сындырдым. Җиткәндер инде...

– Пациент! Мине депрессиягә кертмәгез! Мин сорау бирәм, сез «О’Кей!» дип җавап бирәсез. Һәм шунда ук авызыгызны йомасыз! Башладык... Тормыш ничек?

–О-о-о! Кэй!

– Ә елмаю кайда?

– Минем инде биш ел елмайганым юк.

– Ә мин сезне өйрәтермен. Күз алдыгызга сыйр кисәге китерегез һәм эчтән шул сүзне әйтегез. Китердегезме?

– Әйе.

– Алайса ник елыйсыз?

– Миндә сыйр юк...

– Ярый. Үз үрнәгемдә өйрәтеп карыйм. Әйдәгез, болай... Сез сорыйсыз, ә мин җавап бирәм. Аңлашылдымы?

– Аңлашылды. Доктор, тормышыгыз ничек?.. Ә нигә күзләрегез яшьләнде?.. Сез елыйсыз түгелме соң? Нәрсә булды сезгә?

– Мине... Мине... Ирем ташлады...


– Тыңлагыз мине, ханым...

– Мин ханым түгел! Мин пси... пси... психо...

– Психопаткамы? Ай-яй, катлаулы очрак. Ничек ярдәм итәргә дә белмим. Ә шулай да... Телисезме, ирегезнең ипи шүрлеген җимерәм?

– Телим!!!

– Менә шулай. Уңай якка үзгәреш сизелә. Ә хәзер яшьләрегезне сөртегез дә “Сы-ыйр” дип әйтегез.



Марат БӘШИРОВ



Владимир ТИХОНОВ

ТӨШЕҢДӘ НИ КҮРДЕҢ?

Төш юрау

БИЛЬЯРД. Сез үзегезне лузер итеп тоячаксыз.

СЕБЕРКЕ. Сүгенәчәксез.

БУДИЛЬНИК. Шалтыраса – тиздән уяначаксыз; шалтырамый икән – йоклый бирегез.

КҮГӘРЧЕН. Кулда булса – яхшы хәбәргә, баш өстендә – күңелсез хәлгә.

АКЧА. Төшегездә акча күрәчәксез.

КЕЧКЕНӘ КОНФЕТ. Балалар төше. Әгәр үзегезне әйбәт тотсагыз, төшегездә зуррак конфет күрәчәксез дигәнне аңлата.

ЭШТӘ КҮТӘРҮ. Дошманнарыгызның саны артачак.

МЫЛТЫК. Әгәр төшнең башында стенада асылынып торса, ахырында, һичшиксез, атачак.

ЗОНТИК ТОТКАН БАЛЫК. Кирәкмәгән яңгырга.

СКЛЕРОЗ. Искиткеч гүзәл, ләкин истә калмый торган төш.

ТУН. Хатын күргән очракта, ир, торып, аның нәрсәгә икәнен башка юрамаларда карарга тиеш.

Төшләрне Константин ЧАХИРОВ юрады

НИЗАМИ ЕЛМАЮЛАРЫ

БАШЫҢА КИРӘКМӘСӘ...

Сибгат ага Хәким Казандагы аулак урамнарның берсеннән җәяүләп бара икән. Аның "Башка берни дә кирәкми" дигән яңа җырының яңгырый башлаган чагы (Мансур Мозаффаров музыкасы). Хисчән шагыйрь, үзе дә сизмәстән, җырның көен һәм сүзләрен үзалдына көйләп-җырлап бара:

Башка берни дә кирәкми –
Үзем чапкан печәннәрне...

Шул вакыт ике яшүсмер егет аның бу сүзләрен тыңлаганнан соң:

– Ә-ә, шулаймыни, башыңа берни дә кирәк булмаса, бүрегеңне салдырып китәбез... – диләр дә җыр авторының затлы бүркен чәлдереп качалар! Ә урамда өрфиядәй җиңел кар бөртекләре ява...

СҮЗЕНДӘ ТОРМЫЙ...

Юморист Шәүкәт Галиевнең Татарстан китап нәшриятында баш редактор булып эшләгән чагы. Көннәрнең берендә аның эш бүлмәсенә Нәби Дәүли – атаклы "Яшәү белән үлем арасында" дигән китап авторы килеп керә. Кулъязма папкасын өстәлгә китереп сала да әйтә икән:

– Шәүкәт энем! Картайдым, гомер азагына җиттем, инде бүтән язып та булмас. Соңгы китабым булыр бу. Менә шуны алдагы ел темпланына кертсәгез иде.

Шагыйрь, калын күзлек пыялалары аша елмаеп, болай дигән:

– Нәби ага, сез ел саен шулай дип вәгъдә итәсез, ләкин бер дә сүзегездә тормыйсыз...

Икесе дә рәхәтләнеп көләләр.

ШАТ КҮҢЕЛЛЕ КЕРӘШЕН

Нарат урманлыгында "ИДЕЛ" яшьләр лагеренда яшь иҗат көчләренең республика семинары барган көннәр. (Хәзер мондый чаралар яшьләрнең төшенә дә керми!) Ашханәдән чыктык та, берничә исемле язучылар шәмдәй төз наратлар, шулар янәшәсендәге эскәмияләр рәтеннән барабыз. Бер-бер әкәмәт эзләргә яратучан Марсель Галиев, язарына азык эзләп, маңгаена уч төбе чаклы белдерү кәгазе ябыштырылган эскәмия каршына килеп тукталды. Шуны укыды да, очынып-куанып, Гәрәй Рәхимне (паспортындагы чын исеме – Григорий Родионов) үзе янына чакыра:

– Күр әле, Гәрәй, сине онытмаганнар! Акка кара белән "О, керәшен, о!" дип язып куйганнар...


Гәрәй Рәхим теге язуны укыды да, киң елмаеп, каләмдәшләренә таба борылды:

– Күрәсезме, егетләр, мине монда да бик яхшы беләләр икән! Ышанмыйсызмы, укыгыз әнә...

Кәгазь кисәгенә: "Осторожно – окрашено!" дип, эре хәрефләр белән язылган иде.



Тәнзилә ДАВЫДОВА, 2001 ел.



Пётр КУЛИНИЧ, 1988 ел.



• • •

Менә сезнең ачуыгыз килә, янәмәсе түрәләр һәм депутатлар декларацияләрендә бары тик иске “Копейкаларын”, тагын “хрущёвка” дип аталган фатирларын гына күрсәтәләр, ә үзләре шәхси самолётларында Зәңгәр диңгезләргә очалар. Бу чынлап та дөрес. Декларациядә бит эшләп алган акчалар гына языла.

• • •

Укытучы имтиханда борчылып утыручы студенттан сорый:

– Сез нигә шулкадәр дулкынланасыз, әллә минем сораулардан куркасызмы?

Студент:

– Юк, мин үземнең җавапларымнан куркам!

• • •

– Хөрмәтле әфәнде, сәгать сатам, алыгыз әле! Бу Швейцария сәгатьләренең төгәл копиясе!

– Бирегез. Менә сезгә Рәсәй акчаларының чын копиясе!

• • •

– Ничек өч программист бизнес оештыра ала?

– Берсе вируслар яза, ә икенчесе – антивируслар.

– Ә өченчесе?

– Бөтенесе эшли торган операцион система...


• • •

Командировкага китәр алдыннан хатыны иренә көненә бер генә мәртәбә булса да гөлләргә су сибәргә кушкан. Гөлләргә явым-төшем нормасы хатыны кайтып керер алдыннан – ярты сәгать калгач төшкән.

• • •

Түләүле клиниканың элеккеге табибы военкоматка урнашкан. Бер атна да үтмәгән, куганнар моны – барлык призывниклар каты авыручы булып чыккан, аларны кичекмәстән озак дәваларга һәм кыйммәтле дәвалау курсы үтәргә тиешлеге ачыкланган.







ШӘҺӘРДӘ ЯШӘҮЧЕ БУЛЫП ҖИТЛЕКМӘГӘННӘР

Кадерле "Чаян"! Ундүрт ел элек без, Чебакса бистәсендә яшәүчеләр, шәһәр халкы булып исәпләнә башлагач – безне Казанга куштылар. Хакимият үзенең яңа гражданнарына уңайлырак шартлар тудырасыларын ышандырды: янәмәсе, статус шулай куша. Ләкин бу вакыт эчендә бары прописка гына үзгәрде. Теоретик яктан без – шәһәр кешеләре, ләкин асфальтланмаган юлларда пычрак ерабыз, җыелган чүпләрне бердәнбер чүп мәйданына ташыйбыз, үзәкләштерелгән су белән таэмин итүне телевизордан гына күрәбез. Үзебезнең дәваханәбез юк, юк-бар белешмә өчен дә Казанга барырга кирәк, ә автобусларның йөрү графигы – иртә һәм кич, көндезләрен алар каядыр югала.

Ә күптән түгел генә янәшәбездә яңа торак комплексы төзеләчәген белдек. Димәк, безнең кебек шәһәрдә яшәүчеләр артачак. Башка ТК тәҗрибәсен истә тотып, бернинди дә уңайлыклар булмаячагы ап-ачык...

Чебаксада яшәүчеләр

КАЗАН

ЛЕКСИКОН ҺӘМ ЧЫНБАРЛЫК

Хөрмәтле редакция! Соңгы елларда безнең лексикон шулхәтле тиз үзгәрә башлады. Яңа гына бер сүзгә күнегә башлыйбыз, икенчесе, өченчесе барлыкка килә: кешбек, каршеринг, флешмоб, коливинг һәм башка шундыйраклар... Күптән түгел Кызыл Байракта яшәүчеләр яңа сүз белән танышты...

Авылдан ерак түгел, бик матур елгасы булган бер урында, район Сабан туе узган җирдә, башка көннәрдә дә бу тирәдә яшәүчеләр ял иткәли, балык тоткалый һәм һәрвакыт үзләре артыннан җыештыра. Күптән түгел әлеге тыюлык булып сакланган урын билгесез кешеләр тарафыннан сатып алынган. Инде бу җир хәзер коймa белән әйләндерелгән, шулай итеп, әлеге дә баягы елга буып куелды, инде менә кыргыйларча агачларны кисә башладылар. Нәрсә буласын белгәч, шаккаттык, монда тирә-юньне экологик чиста саклаучылар өчен гостиница төзиләр икән, ә исеме бик тә шәп, яңача яңгырый – Глэмпинг.

Шунысы гаҗәпкә калдыра, экология мәсьәләсен югары дәрәҗәдә үтәү өчен, башка тирәяк табигатен һәлакәт хәленә китерергә кирәк микәнни? Сәер эшләрне башкару өчен бүтән сүзләр табып булмый, ахрысы? Бәлки язарга һәм әйтергә ярамый торганнары кулайрактыр?..

Кызыл Байракта яшәүчеләр

ТУКАЙ районы



Илдар НӘФИЕВ



КҮПКЫРЛЫ АЛМАЗ

Татарның режиссёрлары, сценаристлары, артистлары, юмористлары, җырчылары, баянчылары, прозаиклары, шагыйрьләре арасында башка андый күпкырлы шәхес юктыр, мөгаен. Аның иҗат сандыгында – оештырылган телевизион шоулар, концертлар, эстрада өчен язылган җыр текстлары, нәшриятта басылган китаплар, повестьлар, газета һәм журналлар өчен язылган хикәяләр...

Бу гаҗәп түгел: Алмаз Хәмзин – яшьлек елларыннан эзләнүчән кеше. Ул өч институтта укып карый: авыл хуҗалыгы институты, төзүче-инженерлар институты, педагогика институты. Соңгысында музыка факультетын тәмамлау – аңа берничә һөнәр үзләштерергә мөмкинчелек бирә: композитор, режиссёр, редактор.

Алмаз Хәмзин үзен төрле эшләрдә сынап карый: заводларда, төзелешләрдә, мәктәптә укыта, 13 ел буе Рәфкать Гомәров җитәкчелегендәге "Саз" ансамблендә эштән соң буш вакытында җырлап йөри, филармониядә режиссёр булып эшли. Матбугат өлкәсендә дә кимен куймый – «Казан утлары» журналында редактор вазыйфаларын үти, хәзерге вакытта «Чаян» юмористик журналында – әдәби бүлек хезмәткәре.

Ул үзен таныткан сәхнәне дә ташламый: әледән-әле концертлар оештырып, анда үзе чыгыш ясап йөри. Алмаз – сәхнә өчен язылган күп кенә монологлар һәм юморескалар авторы... Инде килеп, ул – танылган прозаик, «Казан утлары» журналында әледән-әле хикәяләре басылып тора.

Атаклы дустыбызны юбилее белән котлап, аңа бетмәс-төкәнмәс энергия, яңа иҗади уңышлар, сәламәтлек телибез!

«Чаян» журналы хезмәткәрләре.

ТӘКЪДИМ ИТӘМ

Депутатлар,
Намус, вөҗдан, дөреслек диган
Мәгънәләр бармы сездә?
Тәкъдим итәм:
Кертергә бу төшенчәләрне
Конституциябезгә!

Түрәләргә
Талаганнарын кайтарырга
Һәм халыкка бүләргә!
Тәкъдим итәм:
Кайсы илдә акча саклый ул –
Менә шунда сөрергә!

Эшчеләргә,
Завод-фабрикларны кабат
Үзләренә алырга.
Тәкъдим итәм:
Шунсыз илсез калабыз бит,
Ышансаң бу байларга.

Крәстияннар,
Уяныгыз, йоклап ятмагыз,
Каласыз ич сыерсыз.
Тәкъдим итәм:
Фетнә күтәрми генә
Фермер булып куегыз!

Зыялылар,
Йөрмәгез мескенләнеп сорап
Гонорар түләүләрен.
Тәкъдим итәм:
Җәберләүгә закон ясап,
Гафу үтенүләрен.

Хаерчеләр,
Сезгә дә мөрәҗәгать итәм –
Сез дә безнең кешеләр!
Тәкъдим итәм:
Бергәләшеп, иң гадел дәүләт
Без төзергә тиешләр!

ЗУР ХИС!

Үзем уйлап чыгармадым,
Берәүгә дә ят түгел...
Яши торгач, шаклар каттык –
Син дә, мин ярлы бүген.

Кай арада талаганнар,
Алдаганнар безләрне.
Дус та түгел, ят та түгел –
Партийныйлар үзләре.

Хәзер инде болар безгә
Яшәү җаен өйрәтә.
Һәркем үзенчәгә борып,
Кануннарын төзәтә.

Кай арада җыен әтрәк –
Дәү депутат булганнар.
Үзләренең байлыгы аз,
Хатыннары – уңганнар!

Җанкайлары – бизнес-леди,
Губернатор – ирләре.
Ирләренә караганда,
Чиксез зур керемнәре.

Халыкта шундый мәкаль бар:
"Кешенекен санама!"
Безнекен талаган мал ул,
Хәләл түгел ләбаса!..

Искәрмә:
Пенсиясен хатын миннән
Ике меңгә күп ала.
Юктан да кешедә зур хис –
Президентлык уяна!..

ЮБИЛЯРНЫҢ ҖЫРЛАРЫННАН

БАЯНЧЫ ҖЫРЫ

Әлфис Кыямов көе

Өзгәләнеп талый җил яфракны,
Көзләр килгән. Гомерем үткәндер.
Салкын яңгырмы бу, әллә хәлсезлекме?..
Яшәвемнең ахры җиткәндер.
Елама, өзлегерсең, баяным,
Авыр чакта сиңа таяндым.

Безнең язмыш булды бик сагышлы,
Фаҗигаләр сырып ябышты.
Күпләр янды афәт утларында,
Сөю китте ташлап – ялгышты.
Елама, өзлегерсең, баяным,
Авыр чакта сиңа таяндым.

Сине кочып, иңнәремдә йөрттем.
Ташламадым, хәлем ташласа.
Минем әле өч-дүрт минутым бар,
Мине әле синең моң баса.
Елама, өзлегерсең, баяным,
Авыр чакта сиңа таяндым.

Өзгәләнеп талый җил яфракны,
Көзләр килгән. Гомерем үткәндер.
Салкын яңгырмы бу, әллә хәлсезлекме?..
Сулышымның тыны беткәндер.
Елама, өзлегерсең, баяным,
Авыр чакта сиңа таяндым.

ӘТИЛӘРГӘ

Марат Хөснуллин көе

Әтиләргә күп тә кирәк түгел,
Балалары булса әдәпле.
Каян белер идем, әти бәгырем,
Өйрәтмәсәң андый гадәтне.

Әти кебек әти була алсак,
Бурычыбыз җирдә үтәлер.
Әти дигән зур исемне аклап,
Безнең уллар безне күтәрер.

Әтиләргә күп тә кирәк түгел,
Балалары булса һөнәрле.
Белеп алдым синең, әти бәгырем,
Һөнәрлеләр үлмәс дигәнне.

Әти кебек әти була алсак,
Бурычыбыз җирдә үтәлер.
Әти дигән зур исемне аклап,
Безнең уллар безне күтәрер.

Әтиләргә күп тә кирәк түгел,
Балаларын кеше яратса.
Игелекне күреп бездән, әти бәгырем,
Исемеңне синең яңгыратсак.

Әти кебек әти була алсак,
Бурычыбыз җирдә үтәлер.
Әти дигән зур исемне аклап,
Безнең уллар безне күтәрер.

НАФТАЛИН

Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

Сез нафталин исен хәтерлисезме? Элек әбиләр шул нафталинны киемнәргә сибеп, сандыкка салып куялар иде, көя ашамасын дип. Дөрес булгандыр инде. Гел кием алыштырмаганнардыр. Авыр чаклар.

Хәзер менә тагын шул нафталин исе борынга керә башлады әле! Кая барсаң, нафталин исе.

Барлык яшьләр яңа мода киемнән киенгән сыман булды. Ныклабрак карасам, юк, күзләрем ялгышмый. Киемнәре, нәкъ әби сандыгыннан алынган! Берсе белән сөйләшәм:

– Син тормыштан артта калгансың... Бу моданың иң кәттәсе!

Шулайдыр инде, ул пик-моданы без бала чакта ук күргән. Тагын әйләнеп кайткан икән. Миңа да иске киемнәремне сандыктан чыгарырга кирәк. Көнләшеп үләрлек бит. Кыйммәтле киемгә акча туздырасы булмас. Алдың да кидең. Берничәсен сатып җибәрергә дә була. Бераз акча эшләргә дә мөмкин икән. Әлеге модельерлар баш ватып утырмыйлар. Әбиләренең сандыгыннан киемнәрне алалар һәм берәр яңа элемент өстиләр дә, булды! Мода! Кем тикшереп торсын аны, кайчандыр уйлап чыгарылган кием дип.

Мода шулай инде ул, әйләнә дә кайта, әйләнә дә кайта...

Беркөнне китап кибетенә кердем, яңа китаплар юк микән дип.

– Сезне нинди китаплар кызыксындыра: тарих, фантастика, мәхәббәт яки детективмы? – дип сорады сатучы яшь кыз.

Кызык та инде, кайсы кибеткә кермә, сатучылар, консультантлар яныңа шул ук минутта килеп басалар. Элек алай түгел иде, сатучыларны көтеп, арып бетә идек.

– Уйлармын, әлегә танышып кына чыгам, – дип җавап бирдем кызга.

Карыйм, ә ул арттан калмый:

– Менә бу – яшь язучының яңа чыккан китабы. Бестселлер. Күбесе шуны ала.

– Ярар, – дим, – күрсәтегез.

Нишләптер, китапны кулыма алу белән нафталин исе борынга бәрелде. “Бу нәрсә инде тагын? Сандыктагы кием түгел бит, ник нафталин исе килә икән?” дигән уй килде башыма.

Китап битләрен актарам.

“Туктале, мондый китапны укыганым бар иде түгел соң? Тик нишләп язучысы бик яшь?”

Китап таныш булып чыкты. Моннан берничә еллар элек укыганым бар иде. Тик авторы икенче. Персонажларның исемнәре дә алышынган.

Әлегесен кырыйга куеп тордым да, икенчеләрен карый башладым. Берничәсеннән шулай ук нафталин исләре бәреп тора.

Берни алмыйча, чыгып китү юлына борылдым.

– Нәрсә, яңа китапларыбызны ошатмадыгызмы әллә? Ник берсен дә алмадыгыз? Үзегез шактый озак сайландыгыз, – дип үпкәсен белдерде сатучы.

– Юк, ошамады. Бу яңа дип аталган китапларыгызны мин бала чакта ук укыган идем инде. Хәзерге заманга бераз үзгәрткәннәр дә, үзләре язган итеп китап чыгарганнар! Нафталин исе килә алардан! Киемнәрне дә яңа мода дип шулай чыгаралар. Инде китапларны да, үз исемнәренә күчереп язарга тотынганнар.

Кыз, чигәсенә бармагын бөтереп, карап калды...

Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ

БАЙ КҮҢЕЛЛЕЛӘР ҖЫРЫ

Авыр булды. Шулай да без
Айны исән чыгалдык.
Хәлләребез ярыйсы ла,
Хәлләребез чыдарлык!
Ипотекасын түләдек,
Кредитын капладык.
Бакчага аванс күчердек,
Квартплатаны хакладык...
Авыр булды. Акчаларны
Ай күрде, кояш – алды.
Истәлеккә түләүләрдән
Квитанцияләр калды.
Ашалып бетте зарплата,
Алмыйча ризык заты.
Инде авансны көтәбез
Кимереп каты-коты.
Белеп торам, анысы да
Салыр урынын көтә.
Премияләр булмасмы дип,
Көн арты көннәр үтә.
Юк-бар ризык-фәләненнән
Тешләрем бетте какшап.
Билем буып, эчем уып,
Йөрим буш кесә капшап.
Эчемдә бүреләр улый,
Кесәмдә – җилләр исә.
Бурычларым – вагон-вагон,
Кредитым әллә ничә.
Бу язганымны "Чаян"га
Гонорарга сатармын.
Мин дә сезнең шикелле үк
Бай күңелле татармын.



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 9 (1922) сентябрь 2022

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе
«ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре,
Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләре агентлыгы
ярдәмендә оештырылган.
Журнал
Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы,
йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша
язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның
ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү
хокукына ия.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 01.09.2022 ел.
Тираж – 2661 Заказ О-2487

**Редакциянең адресы: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.**

Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.

E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru

Бәясе ирекле

16+

Михаил ЛАРИЧЕВ



Михаил Николаевич Пушкин шәһәрендә яши. Ул Фрунзе исемендәге югары хәрби-диңгез училищесын тәмамлаган, ләкин чиксез диңгез киңлекләрен генә түгел, ә күпсанлы укучыларның йөрәкләрен дә үзенә буйсындырган. Карикатура аның икенче һөнәре булып киткән.

«Чаян»да беренче рәсемен ул 1982 елда бастырган. Соңрак Петербургтагы «Вокруг смеха» белән хезмәттәшлек иткән, әмма «Чаян»га әлегәчә тугры калган. Бу вернисаж – моның ачык дәлиле.









4612750670080